**ГЛАВА НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2023 елның «06» февраленнән | № 2

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү оештыру буенча эшче төркем төзү турында

«Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизация турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указына таянып, мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү максатларында карар бирәм:

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем төзергә (алга таба текст буенча - эшче төркем).

2. Расларга:

эшче төркем составын (1 нче кушымта);

эшче төркем турында нигезләмәне (2 нче кушымта);

махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә ярдәм итү чаралары планын (3 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында рәсми сайтында бастырып чыгарырга: http:/novosheshminsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгының
2023 елның «06» февраленнән
2 номерлы карарына
1 нче кушымта

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү оештыру буенча эшче төркем
составы

Эшче төркем рәисе:

| | | |
|---|---|---|
| Козлов Вячеслав Михайлович | - | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы |

Эшче төркем җитәкчесе урынбасарлары:

| | | |
|---|---|---|
| Попкова Надежда Ивановна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары |
| Фасахов Ринат Рифгать улы | - | Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |

Комиссия секретаре:

| | | |
|---|---|---|
| Зевакина Ольга Вениаминовна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мобилизация эше буенча ярдәмчесе (килешү буенча) |

Эшче төркем әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Бутина Анна Ивановна | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Васильева Светлана Анатольевна | - | «Единая Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Яңа Чишмә җирле бүлеге башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Гурьева Наталья Николаевна | - | Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының Яңа Чишмә муниципаль районындагы социаль |

| | | |
|---|---|---|
| | | яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Еронтьев Александр Леонидович | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары (социаль мәсьәләләр буенча) (килешү буенча) |
| Исхакова Луиза Камил кызы | - | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары (икътисад буенча) (килешү буенча) |
| Калмыков Виктор Николаевич | - | Татарстан Республикасы запастагы чик сакчыларының бергәлеге һәм хәрби хәрәкәтләр район иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (килешү буенча) |
| Карпов Александр Михайлович | - | Карпов Александр Михайлович крестьян фермерлык хуҗалыгы башлыгы - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә авыл җирлеге советы депутаты (килешү буенча) |
| Козлов Александр Евгеньевич | - | Козлов Александр Евгеньевич крестьян фермерлык хуҗалыгы башлыгы (килешү буенча) |
| Ситдиков Ришат Фәйзерахман улы | - | шәхси эшмәкәр (килешү буенча) |
| Слимова Ирина Михайловна | - | Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең Яңа Чишмә муниципаль районында җәмәгать ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары | - | карала торган мәсьәләгә карап |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгының
2023 елның «06» февраленнән
2 номерлы карарына
2 нче кушымта

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү оештыру буенча эшче төркем турында нигезләмә

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә мәгариф, социаль тәэминат, торак-коммуналь хезмәтләр, сәламәтлек саклау өлкәләрендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә даими яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучы Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр һәм затлар, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хәрби хезмәт узучы гражданнар, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Тимер» һәм «Алга» батальоннарында хәрби хезмәт узучы гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүчеләр, махсус хәрби операция уздыру зонасына командировкага җибәрелгән Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре (алга таба – махсус хәрби операциядә катнашучылар)арасына кергән гражданнарның түбәндә күрсәтелгән гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтүне (алга таба - ярдәм) оештыру максатларында оештырыла:

махсус хәрби операциядә катнашучының хатыны;

махсус хәрби операциядә катнашучыларның 18 яшькә җитмәгән, бу яшьтән өлкәнрәк 18 яшькә җиткәнче инвалидка әйләнгән балалары, шулай ук белем бирү оешмаларында көндезге бүлектә белем алучы балалар - уку тәмамланганчыга кадәр, әмма алар 23 яшькә җиткәнче;

махсус хәрби операциядә катнашучының ата-анасы яисә балигъ

булганчыга кадәр аны тәрбияләгән опекуннар (попечительләр);

махсус хәрби операциядә катнашучы белән бергә яшәүче башка затлар.

2. Эш төркеме үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының норматив хокукый актлары белән җитәкчелек итә.

3. Эшче төркемнең төп функцияләре түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә даими яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучыларның ярдәм күрсәтүгә мохтаҗ гаиләләр әгъзаларын ачыклау;

махсус хәрби операциядә катнашучының гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү чараларын үтәүне оештыру;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә даими яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү кирәклеге турында мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү, торак-коммуналь хуҗалык, сәламәтлек саклау органнарына һәм оешмаларына мәгълүмат бирү;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә даими яшәүче махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларына ярдәм күрсәтү өчен ирекле (волонтерлык) оешмаларын җәлеп итүне оештыру;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләр әгъзаларына ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыруны тикшереп тору.

4. Эшче төркем турында нигезләмә һәм эшче төркемнең персональ составы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.

Эшче төркем составына эшче төркем рәисе, эшче төркем рәисенең ике урынбасары, эшче төркем секретаре һәм эшче төркем әгъзалары керә.

Эшче төркем рәисе - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы (аның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы зат).

5. Эшче төркем рәисе эшче төркем эшчәнлегенә гомуми җитәкчелекне гамәлгә ашыра, эшче төркем әгъзаларына йөкләмәләр бирә, эшче төркем утырышын уздыру датасын, урынын һәм вакытын билгели, эшче төркем тарафыннан башкарыла торган функцияләр кысаларында башка мәсьәләләрне хәл итә.

6. Эшче төркем секретаре эш төркеме карарларының, эшче төркем рәисе йөкләмәләренең үтәлешен тикшереп тора, эшче төркемнең утырышлары беркетмәләрен рәсмиләштерә, эшче төркем рәисенең башка йөкләмәләрен үти.

7. Эшче төркем утырышлары кирәк булган саен утырыш рәвешендә уздырыла. Эшче төркем утырышлары видео-конференц-элемтә форматында үткәрелергә мөмкин.

Махсус хәрби операциядә катнашучы гаилә әгъзасыннан ярдәм күрсәтү турындагы гариза эшче төркем тарафыннан 15 календарь көн дәвамында карала.

Эшче төркем утырышын эшче төркем рәисе яисә аның кушуы буенча эшче төркем рәисе урынбасарларының берсе алып бара.

Эшче төркем карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул эшче төркем утырышында рәислек итүче һәм эшче төркем секретаре тарафыннан имзалана.

Кирәк булганда эшче төркеме утырышына иҗтимагый һәм башка оешмалар вәкилләре, башка затлар чакырылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгының
2023 елның «06» февраленнән
2 номерлы карарына
3 нче кушымта

Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә ярдәм итү буенча чаралар планы

| № т/б | Чара исеме | Җаваплы |
|---|---|---|
| Балалар өчен | | |
| 1 | Муниципаль мәгариф оешмаларында 1-11 сыйныф укучыларына бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү | Еронтьев А.Л., Бутина А.И. |
| 2 | Муниципаль балалар бакчаларына бушлай йөрү | Еронтьев А.Л., Бутина А.И. |
| 3 | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма хакимияте органнары карамагындагы мәктәпләрдә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә түгәрәкләрдә һәм секцияләрдә шөгыльләнү өчен түләүдән азат итү | Еронтьев А.Л., Бутина А.И. |
| 4 | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендәге муниципаль мәдәният һәм ял итү учреждениеләре музейларына, концертларына гаилә әгъзаларына бушлай керү | Еронтьев А.Л., Носова Г.А. |
| 5 | «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенә махсус хәрби операциядә катнашучы гаиләсенең барлык әгъзаларына бушлай йөрү | Еронтьев А.Л., Магомедова М.А. |
| 6 | Муниципаль лагерьларга юлламаларны сатып алуда чирата беренче торуны тәэмин итәргә. | Еронтьев А.Л., Бутина А.И., Магомедова М.А. |
| Өлкән яшьтәге туганнары, инвалидлар һәм инвалид балалар өчен | | |
| 1 | Халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгенә, гаиләгә ярдәм итү үзәгенә, мобилизацияләнгән гражданнарның якын туганнарының балаларына (әни, әти, әби, бабай һәм инвалид бала) бушлай өйдә хезмәт күрсәтү | Еронтьев А.Л., Гурьева Н.Н. (килешү буенча) |
| 2 | Фатир, йорт алды участогын җыештыру буенча | Еронтьев А.Л., |

| | | |
|---|---|---|
| | волонтерлык ярдәме оештыру | Магомедова М.А., Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| Хезмәткә сәләтле яшьтәге тормыш иптәше һәм балалары өчен | | |
| 1 | Эш эзләүдә ярдәм итү | Исхакова Л.К., Еронтьев А.Л., Хөснуллина Р.Г. (килешү буенча), Авыл җирлекләре башлыклары (килешү буенча) |
| 2 | Һөнәри белем һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру | Исхакова Л.К., Еронтьев А.Л., Хөснуллина Р.Г. |
| Гаиләнең барлык әгъзалары өчен | | |
| 1 | Гаиләсе алырга хокуклы социаль һәм башка түләүләрне, социаль ярдәм чараларын рәсмиләштерүдә ярдәм итү | Еронтьев А.Л., Гурьева Н.Н. (килешү буенча) |
| 2 | Медицина ярдәме күрсәтү | Еронтьев А.Л., Роменская Н.А. (килешү буенча) |